ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЕЛАБУЖСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АЛАБУГА МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

10.02.2022 № 116

Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының «2022 елга Алабуга муниципаль районының муниципаль гомуми белем бирү оешмаларында укучыларның туклануын тәэмин итү турында» 2021 елның 29 декабрендәге 1859 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының «2022 елга Алабуга муниципаль районының муниципаль гомуми белем бирү оешмаларында укучыларның туклануын тәэмин итү турында» 2021 елның 29 декабрендәге 1859 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 2 пунктның 6 абзацында «69 сум» сүзләрен «73 сум» сүзләренә алмаштырырга;

1.2. 2 пунктның 7 абзацын төшереп калдырырга.

1.3. 3.1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.1 Түбәндәге балаларны ике тапкыр бушлай кайнар ризык белән тәэмин итәргә:

- сәламәтлеге ягыннан мөмкинлекләре чикләнгән балаларны;
- инвалид балаларны.

Сәламәтлеге ягыннан мөмкинлекләре чикләнгән бала (укучы) статусы медик-социаль экспертиза (МСЭ) һәм психологик-медик-педагогик комиссия (ПМПК) тарафыннан билгеләнә.

Бер укучыга көненә ике тапкыр кайнар ризык белән туклануның уртача бәясен түбәндәгечә билгеләргә:

1-4 сыйныфта укучы балаларга – 80,25 сум, 5–11 сыйныфта укучы балаларга – 71,40 сум күләмендә.

Шикәр диабеты белән авыручы балаларны индивидуаль туклану белән тәэмин итәргә.»

2. Әлеге карар рәсми бастырып чыгарылырга тиеш.
3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль үсеш буенча урынбасары Л.Р. Яһудинага йөкләргә.

Җитәкче Л.Ф. Нургаянов